**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**ШЕТНЕВО-ТУЛУШСКОГО**
**сельского поселения**
**Рыбно-Слободского**
**муниципального района**
**422644, с.Шетнево-Тулуши**
**ул.М.Джалиля, д.18,**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Балык Бистәсе**
**муниципаль районы**
**ЮГАРЫ ЫРГА авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**
**422644, Шетнево-Тулуш,**
**М.Җәлил урамы, 18.**

**Тел.: (884 361) 27-451, факс: (884 361) 27-451. электронный адресl: Stul.Rs@tatar.ru**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

от 01 ноября 2023 года с. Шетнево-Тулуши № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлегенең
Яңа Ырга
авылының торак пунктында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану
мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы " Югары Ырга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлегенең Яңа Ырга авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2023 елның 15 ноябрендә 8 сәгатькә гражданнар җыенын үткәрүне билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге составына керүче Яңа Ырга авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, беренче торкем инвалидлардан гайре), 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы»:

- Яңа Ырга авылында юлларны кышкы карап тоту;

- су системасы

- Югары Ырга авылында юлларны төзекләндерү

« ӘЙЕ» “ЮК”

3. Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә кирәк.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Югары Ырга авылы, М.Җәлил урамы, 18 нче йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Ырга авылы,Мәктәп урамы,48 йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Югары Ырга авыл җирлеге Башлыгы Р.Н.Багаутдинов